КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 28 август г.Казань № 728

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чулпан» төбәк әһәмиятендәге ландшафтлы профильле дәүләт табигый тыюлыгы турында нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 19 август, 379 нчы карары белән расланган төбәк әһәмиятендәге ландшафтлы профильле дәүләт табигый тыюлыгы турында нигезләмәнең 16 пункты гамәлдә булуны вакытлыча туктатып тору хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәтләре күрсәтү өчен тарифларга махсус өстәмә түләүләр кулланудан алынган акча хисабыннан финанслана торган 2017 елга Татарстан Республикасын газлаштыру программасын раслау турында» 2016 ел, 9 декабрь, 912 нче карары нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Маҗар авылына Д160 мм югары басымлы газ үткәргечтән тармаклану» проектын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Маҗар авылына Д160 мм югары басымлы газ үткәргечтән тармаклану» проектын тормышка ашыру срогына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чулпан» төбәк әһәмиятендәге ландшафтлы профильле дәүләт табигый тыюлыгы турында нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 19 август, 379 нчы карары белән расланган төбәк әһәмиятендәге ландшафтлы профильле дәүләт табигый тыюлыгы турында нигезләмәнең 16 пункты гамәлен тыюлыкның эшләве, уртак кулланылыштагы юллардан читтә автомототранспорт йөрү һәм туктап тору белән бәйле торба

үткәргечләр һәм башка коммуникацияләр төзелешен тыю өлешендә махсус боерыкка кадәр туктатып торырга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин